Бүгенге көндә «татар педагогик фикере», «татар педагогикасы» төшенчәләрен аңлауда беркадәр төрлелек күзәтелә. Беренче караш буенча, татар педагогик фикеренең нигезен татар мәгарифенең үсешен тәэмин иткән, аның эчтәлеген, тарихын төрле яклап өйрәнгән һәм күзалларга мөмкинлек биргән, татар телендә язылган хезмәтләрдә чагылыш тапкан фикерләр тәшкил итә. Кайбер очракларда бары тик педагогның милләтенә карап кына аның урынын билгеләү дә очрый (татар милләтеннән булган, әмма гомумән мәгариф проблемаларына багышланган хезмәтләр язучы галимнәр). Төрле чорларда татар мәгарифе үсешенә өлеш керткән башка милләт педагогларының (XVIII-XIX гасырларда хезмәт күрсәткән рус һәм европа галимнәре В.Радлов, К.Фукс, Н.Бобровников һ.б., татар мәгарифе өлкәсендә эшләүче бүгенге чор галимнәре В.М.Беркутов, И.Л.Литвинов һ.б.) шулай ук татар педагогик фикере үсешендә билгеле урыннары бар. Безнең карашка, биредә төп үлчәм булып хезмәтләрнең татар мәгарифе мәсьәләләренә багышлануы торырга тиеш.

Татар педагогик фикере, татар мәгарифе һәм мәктәбе тарихыннан аермалы буларак, халыкның төрле чорларда тәрбия, белем бирүгә, мәгариф үсешенә йогынты ясаган һәм

бер үк вакытта мәгариф үсешен, аның үзенчәлекләрен чагылдырган фикерләре ул. Педагогик фикер аерым педагогларның хезмәтләрендә, рәсми документларда чагылыш таба, төрле чорларда татар мәгарифенең җәмгыять үсешендә тоткан урынын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Татар педагогик фикерен өйрәнүдә әһәмиятле ысулларының тагын берсе – фәнни-гамәли юнәлештәге басмалар әзерләү. Болар: татар галимнәренең педагогика, мәгариф, белем бирү һәм тәрбиягә багышланган хезмәтләрен бастырып чыгару, төрле авторларның хезмәтләреннән тупланган җыентыклар әзерләү һ.б. Әлеге юнәлештә башкарылган уникаль хезмәтләр арасында «Татар педагогик фикере антологиясе»[1] дә бар.

«Татар энциклопедиясе»ндә «антология» төшенчәсенә «төрле авторларның сайланма әдәби әсәрләре җыентыгы» дип аңлатма бирелгән [13: 174]. Ләкин заманча антологияләрне әдәби әсәрләр белән генә чикләү мөмкин түгел. Гомумән алганда, антология – ул аерым бер халыкның яисә илнең (республиканың) билгеле бер юнәлешкә караган фикер үсешен күрсәтә алырлык итеп тупланган хезмәтләрнең, әсәрләрнең һәм мәкаләләрнең академик басмасы. Авторның антологиягә кертелгән хезмәте (әсәре) фәнни, методик, фәнни-публицистик һәм фәнни-популяр характерда булырга мөмкин. Шулай ук билгеле бер шартларда әдәби әсәрләрне, фольклор үрнәкләрен дә кертү максатка ярашлы. Бу принциплар «Татар педагогик фикере антологиясе»н төзегәндә нигез итеп алынды.

Педагогик фикер антологияләренең, чагыштырмача яңа юнәлеш булса да, үзенчәлекле тарихы бар. XX гасырның 80 нче елларында беренче тапкыр серия буларак күптомлык СССР халыклары педагогик фикере антологиясе чыга башлый. Бу басмалар борынгы чорлардан алып XX гасырның 80 нче елларына кадәр булган вакыт аралыгында СССР күләмендә педагогик фикер үсеше тарихын яктыртуда беренче адым булып тора. Аның беренче томы Борынгы Русь һәм XIV-XVII гасырларда рус дәүләтендә педагогик фикер үсешен тасвирлауга багышланган [14]. Моннан соң дөнья күргән басмалар союздаш, аерым алганда, Беларуссия, Украина, Грузия, Кыргызстан, Үзбәкстан һ.б. республикаларның педагогик мирасын тәкъдим итә [15; 16; 17; 18; 19; 20].

Гомумән алганда, бу антологияләрне нәшер итүдә төп максат булып һәр совет республикасының педагогик мирасын туплау һәм системага салу, борынгы заманнардан алып әлеге басмалар дөнья күргән чоргача аерым халыкларның тәрбия һәм белем бирүгә караган карашлары, мәгариф үсешенең торышы белән таныштырудан гыйбарәт. Проект авторларының фикеренчә, антологияләрне эшләү күпмилләтле илнең педагогик мирасын байлыгын һәм төрлелеген күрсәтергә, аны танытырга мөмкинлек бирәчәк [14: 5]. Шул ук вакытта, төрле халыкларның педагогик фикере үсешендәге охшашлыклар белән беррәттән (ә алар, билгеле булганча, совет чоры педагогикасы үсешендә шактый), беркадәр милли үзенчәлекләрне дә күрсәтү мөмкинлеге ачылачак [14: 5]. Басмаларның яңалыгы да, беренче чиратта, шуның белән билгеләнә. 80 елларның икенче яртысында басылып чыккан антологияләр, совет идеологиясенә нигезләнсәләр дә, һәрбер милләткә индивидуаль якын килү, аларның үзенчәлекләрен исәпкә алырга тырышу ягыннан аерылып торалар.

СССР Педагогия фәннәре академиясе җитәкчелегендә, үзәкләштерелгән басмаханәдә (Мәскәүдәге «Педагогика» нәшриятында), бер үк форматта басылган антологияләрнең төзелеш принциплары нигездә бер үк төрле. Кайбер аермалыклар (басмаларда теге яки бу якка зуррак урын бирелү) халыкның педагогик фикер үсешенең аерым закончалыклары, педагогика фәненең үсеш дәрәҗәсе белән билгеләнә. Барлык антологияләр педагогик фикер үсешенең аерылгысыз өлеше булган халык педагогикасы бүлегеннән башланып китә. Ләкин төрле антологияләрдә «халык педагогикасы» бүлегенең күләме төрлечәрәк. Чагыштыру өчен: грузин, беларус, украин педагогик фикере антологияләрендә бу бүлек кыскача (20-30 бит күләмендә) яктыртылса, кыргызларда ул шактый зур күләмле (75 бит). Авторлар моны кайбер халыкларның күпгасырлык милли традицияләрне тикшерү (бу очракта педагогик хезмәтләр күз алдында тотыла) мөмкинлеге булу, ә кайберләрендә (әйтик, кыргызларда) бу мөмкинлекнең XX гасыр белән генә чикләнүе, кыргыз халкында язу барлыкка килүнең революциядән соңгы чор белән генә бәйле булуы, шул сәбәпле революциягә кадәрге чорда төп педагогик

[1] «Татар педагогик фикере антологиясе» урынына алга таба «Антология» термины кулланылачак.

фикер чыганагы булып халык педагогикасы һәм акыннар иҗаты торуы белән аңлаталар [14: 5].

Гомумән алганда, кайбер җитешсезлекләре булуга карамастан, алда искә алынган антологияләрнең әһәмиятен киметү һич мөмкин түгел. Алар шул заманга хас булган бүленеш нигезендә аерым союздаш республикаларда педагогик фикер үсешен күзалларга мөмкинлек бирәләр. Әмма бер система нигезендә һәр республика өчен дә төзелмәүләре, Россиядәге автоном республикаларны һәм өлкәләрне, барлык милләтләрне колачламаулары сәбәпле, илдәге педагогик фикер үсешен тулысынча күрсәтә алмыйлар. Икенче зур җитешсезлек милли үзенчәлекләргә игътибарның бик аз булуы белән билгеләнә. Мәсәлән, Россия педагогик фикере антологияләре, кайсы чорны колачлавына карамастан, бары тик рус педагогик фикере үсешен генә чагылдыра [14; 21]. «XIX гасырның беренче яртысы педагогик фикере антологиясе»ндә Россиядә яшәүче башка милләтләрнең педагогик фикере бөтенләй чагылыш тапмаган. Украиннар төзегән антология украин халкының педагогик карашлары нигезендә төзелсә, Үзбәкстан ССР антологиясендә гомумән республикада яшәгән һәм хезмәт иткән төрле педагогларның хезмәтләре тәкъдим ителә. Соңгысы шул заман өчен яраклы булса да, хәзерге чорда төп принцип була алмый, чөнки заман фәне өчен, беренче чиратта, аерым милләт һәм халыкларның педагогик фикере үсешен өйрәнү кыйммәтле һәм зур кызыксыну тудыра. Бүген аерымлыкларны өйрәнү нигезендә гомумиләштерү, ягъни аерым милләтләрнең педагогик мирасын өйрәнеп, аларның гомумпедагогик киңлектә токкан урынын ачыклау мөһим.

Гомумпедагогик (ил күләмендәге) фикер киңлегеннән читтә калган милли педагогикалар үсешен күрсәтү тарихи дөреслекне торгызу өчен дә әһәмиятле. Нәкъ менә шул сәбәпле Россиядә яшәүче башка милләтләр – татарлар, башкортлар, марилар, чувашлар, якутлар, тувалылар һ.б. ның педагогик фикерен туплау, өйрәнү мөһим. Әмма, кызганычка каршы, бу өлкәгә бүгенге көндә игътибар бик аз бирелә. Татар педагогик фикерен өйрәнүдә иң мөһим ысулларның берсе булган Антология иң беренче чиратта әнә шул бушлыкны тутыру, татар халкының мәгариф өлкәсендәге күпгасырлык мирасын киң татар җәмәгатьчелегенә тәкъдим итү мөмкинлеген тудырачак. Алдагы бурычларның берсе булып татар педагогикасы кыйммәтләрен Россия югарылыгында һәм дөнья күләмендә (рус һәм инглиз теленә тәрҗемә итү аша) таныту тора.

Гомумән алганда, «Татар педагогик фикере антологиясе»н төзегәндә, үрнәк буларак алда санап үтелгән басмалар файдаланылса да, аларга тәнкыйди караш булдырылды. Антологияләрдә күзәтелгән җитешсезлекләрне булдырмау максаты белән, антологияне төзүнең методологик нигезләре, концепциясе эшләнде, төп принциплар билгеләнде [22]. Төп игътибар татар педагогик фикере үсеше үзенчәлекләренә бирелде, бүгенге заман фән казанышларына нигезләнелде.

Безнең карашка, теге яки бу халыкның педагогик фикере антологиясе аның милли үзаңы формалашу үзенчәлекләрен, тарихын, педагогика фәненең үсеш кануннарын һәм казанышларын яктыртырга тиеш. «СССР халыклары педагогик фикере антологиясе» рубрикасы астында дөнья күргән басмалар, әйтеп узганча, бу принципны истә тотып эшләнмәгәннәр. Бары тик бер генә антология – рус педагогик фикере (ул Россия исеме астында бирелгән) антологиясе руслардагы педагогик фикер үсешен тулаем күрсәтә алган. Ул бик җентекле итеп, чорларга бүлеп өйрәнелгән, шуның нәтиҗәсе буларак, берничә кисәктән торган басмалар дөнья күргән [14; 23; 21; 24].

Татар педагогик фикерен өйрәнү нәтиҗәсендә эшләнгән Антология төзүнең төп максаты – бай тарихлы, элек-электән үк гыйлем алуга омтылган, үз исәбенә мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, укый-яза белү дәрәҗәсе буенча Россиядәге башка милләтләр арасында алгы урыннарны яулаган татар милләтенең педагогик мирасын барлау, педагогик фикер үсешенең үзенчәлекләрен ачыклау, бөтен дөнья буйлап таралган милләттәшләребезнең педагогик карашларын туплау, аларның гомумпедагогик киңлеккә керткән өлешен ачыклау. Дөрес, соңгы елларда дөнья күргән Татар энциклопедиясе [13] татар мәгарифе тарихын беркадәр күзалларга мөмкинлек тудырды. Әмма ул, мәгълүмати характердагы басма булып, педагогик фикер үсешен тулаем һәм үсештә чагылдырмый. Антология беренче чиратта шул мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелгән.

Билгеле булганча, татар педагогик фикерен билгеләүче иң мөһим өлешләрнең берсе – «тәрбия өлкәсендә яшәп килгән карашлар, аның тәҗрибәгә нигезләнгән тәрбияләү, укыту

алымнары һәм чаралары, буыннан-буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәре, халык өйрәтүләре, аның тәрбия тәҗрибәсе»н [25: 5] тәшкил иткән татар халык педагогикасы. Бу фикер, әлбәттә, Антологиядә дә чагылыш таба.

Татар педагогик фикеренең үсеш тарихын өйрәнгәндә, тарихи хронологиягә һәм эчтәлеккә бәйле рәвештә аерым чорларны билгеләргә була. Я.И.Ханбиков, мәсәлән, Идел Болгары (XI-XIII), Алтын Урда (XIII-XIV), Казан ханлыгы (XV-XVI) чорларына бүлә. Педагогик фикер үсешендәге шуннан соңгы чорлар тематик принципка нигезләнә. Автор рус дәүләтенә кушылу, дини реформация, мәгърифәтчелек хәрәкәте, җәдитчелек, революцион-демократик педагогика дигән бүлекләрне күрсәтә [7: 6-15]. Әлбәттә, бу принципны бүгенге көндә тулысынча нигез итеп алу мөмкин түгел. Тикшеренүләр татар педагогик фикере үсешендә борынгы төрки, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, XVI-XVIII гасырлар, XIX-XX гасырның беренче чиреген, XX гасырның 20-60 нчы елларын, 60-80 еллар азагын һәм 90 нчы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр булган чорларны аеру мөмкинлеген раслый. Әлеге бүленеш Антологиядә дә чагылыш тапты.

Билгеле булганча, татар педагогик фикере үсешенең башлангыч дәвере борынгы төрки чор – төрки каганлыкка барып тоташа. VII гасыр ахырында манихей, зороастризм, брахма, будда кебек дөнья диннәре һәм мәдәниятләре белән таныш булган борынгы төркиләр арасында ислам дине тарала башлау мәгариф үсешендә дә чагылыш таба: төркиләрдә мәгариф гомумислам мәгариф системасының бер өлеше буларак үсеш ала. Көнчыгыш дини белем бирү системасындагы кебек үк, укыту эше дини белемле остазларга йөкләнә. Кече яшьтән үк баланы тормыш тәҗрибәсе күнекмәләренә өйрәтү, дала табигатенә сакчыл караш тәрбияләү – төркиләрнең педагогик карашларының нигезен тәшкил иткән. Хан сарае каршында мәктәпләр эшләгән, димәк, төрки аксөякләр арасында белемле булу зур мәртәбә саналган. Алар, үз илләрендә белем алу белән канәгатьләнмичә, чит илләрдә дә укыганнар. Шул заман өчен Кытайда белем алу иң югары һәм мактаулы, дәрәҗәле саналган [26: 60].

Борынгы төркиләрдә беренче урынга акыл, аннан соң гына көч куела. Шулай ук тарихка, бабалар рухына тугрылык саклау төп кануннарның берсе була, яшь буын борынгы бабалар үрнәгендә тәрбияләнә. Борынгы төркиләрнең педагогик традицияләре татар һәм башка төрки халыкларның мәгариф үсешенә нигез салган уртак мирас булып тора. Антологиядә «Халык педагогикасы» бүлегеннән соң «Борынгы төрки чорда мәгариф (VI-IX гасырлар)» бүлеге бирелү дә шуның белән билгеләнә. Анда Күлтәгин һәм Төньюкук ташъязмалары (732-734), Турфан язмалары (V-IX гасырлар), Ырыг битиг (IX гасыр ахыры – X гасыр башы) текстларындагы педагогик фикерне чагылдырган өзекләр сайлап бирелде.

Татар педагогик фикере үсешен билгеләүче иң төп үзенчәлекләрнең берсе булып, аның, бер яктан, татар милли мәгариф идеяләрен чагылдыруы булса, икенче яктан, башка халык һәм ил мәгарифләре белән үрелеп үсүе тора. Мәгариф өлкәсендәге фикер алмашу һәм тәҗрибә уртаклашу, мәдәниятара багланышлар бик борынгы заманнарда ук башланып, бүгенге көндә дә дәвам итә.

Төрле чорларда татар педагогикасы үсешен дөнья диннәренең әхлакый нормалары һәм кануннары, шулай ук татарлар борынгы заманнардан ук аралашып, үзара тәэсир итешеп яшәгән күрше дәүләт һәм халыкларның (Кытай империясе, Һиндыстан, Урта Азия, Иран, гарәп дөньясы, Төркия, Россия, Европа халыклары) тәрбия өлкәсендәге карашларыннан, укыту һәм тәрбия системалары йогынтысыннан аерып карау мөмкин түгел [27: 57]. Бу борынгы чорларда ук башка илләргә барып белем эстәү яисә чит ил галимнәрен укыту һәм белем бирү эшенә җәлеп итүдә чагылыш таба (мәсәлән, Мәккәдән килеп Болгарда мәдрәсә ачкан Сөләйман Хуҗа турында билгеле [28: 78]). Мәгариф өлкәсендәге мондый алмашулар халкыбыз, аның тәрбия, белем бирү системасы турындагы мәгълүматның дөньякүләм таралуына китергән. Антологиянең беренче томында кайбер бүлекләрдән соң төрки халыкларның борынгы бабаларында мәгариф, гыйлем, тәрбия турында чит ил галимнәренең әйткән сүзләрен туплап бирү шул фикерне тагын бер тапкыр раслау максатыннан чыгып эшләнде. Шартлы рәвештә «Чит ил галимнәре татарлар һәм татар мәгарифе турында» дип аталган бу бүлекчәләрдә һуннар, төркиләр тормышы, аларда тәрбия һәм гыйлемлелек турында әйтелә. Мисал өчен, «Борынгы төрки чорда мәгариф (VI-IX гасырлар)» бүлегеннән соң Борынгы Рим тарихчысы Аммиан Марцеллин (330-391), X гасыр гарәп географы

Әбу Дулаф, гарәп язучысы Әбу Госман Әмр бине Бәхр әл-Җахиз (775-868), Кытай тарихчысы Сымы Цянь (безнен эрага кадәр 145/135 – 86 еллар) һ.б. бик күп укымышлыларның борынгы төркиләрдә махсус гыйбадәтханәләр булуы, язу өчен камыштан файдаланулары, әхлак сыйфатлары – берберләренә карата ярдәмчеллек, хезмәт сөючәнлек, балаларга карата йомшак мөгаләмәдә булулары турындагы һ.б. кызыклы мәгълүматлар бирелә [29; 34-37]. Бу, безнең карашка, басманың кыйммәтен сизелерлек дәрәҗәдә арттыра.

Татар педагогик фикере үсешен, бигрәк тә XIX-XX гасыр башын, рус һәм Европа галим-педагоглары эшчәнлегеннән аерып карап булмый. Татарларның уку-укытуга карашларын, гыйлем һәм тәрбиягә булган мөнәсәбәтләрен Россия күләмендә таныткан галимнәр – К.Фукс, Я.Коблов, В.Радлов, татар тел гыйлеме, татар телен укыту һәм башка телләргә өйрәтү тарафдарлары М.Иванов, Н.Катанов, Н.Бобровников, В.Богородицкий һ.б. хезмәтләре дә татар педагогик фикере үсешенең үзенчәлекләрен күрсәтүче фактор буларак каралды.

Татар педагогик фикере үсешен өйрәнүдә татарларның башка халыкларның мәгарифенә керткән өлешен билгеләү әһәмиятле. Төркестан далаларында аң-белем тараткан татар мәгърифәтчеләре, хатын-кыз педагоглар турында яхшы билгеле. Мисал өчен, 1909-1916 елларда Сәмәрканд мәктәпләрендә укыткан мөгаллимә К.Мозаффарова, казакъ далаларында балаларга белем биргән М.Акмулла, Ш.Бабич һ.б., Төркестанда җәдит мәктәпләре ачуда ярдәм иткән татарлар турындагы мәгълүматлар «Татар педагогик фикере антологиясе»нә кертелде. Бу мәгълүматлар, кызганыч, башка (мисал өчен, кыргыз, үзбәк һ.б. Урта Азия республикаларына багышланган) антологияләрдә урын алмаган.

XVII гасырга кадәр татарларда фәннәр үсеше синкретик характерда булу сәбәпле, гыйлем һәм тәрбиягә караган фикерләр дә нигездә әдәби әсәрләрдә чагылыш таба. Бу үзенчәлек Антология төзегәндә дә искә алынды. Беренче томда күпсанлы әдәби текстларның (Кол Гали, Сәиф Сараи, Котб, Мөхәммәдъяр, Г.Кандалый һ.б.) бирелүе шуның белән аңлатыла.

Татар педагогик фикере үсешенә ислам рухи-әхлакый кыйммәтләренең тәэсире аеруча көчле булган. Бу очраклы күренеш түгел. Татар мәгариф системасы нәкъ менә мөселман цивилизациясе йогынтысында чәчәк аткан. Дәүләтчелекне югалтканнан соң да, мөселман уку-укыту системасы татар халкының рухи асылын саклап калырга ярдәм иткән. Бу Антологиянең нигезен тәшкил иткән үзенчәлекләрнең берсе. Шуны истә тотып, басмада мөселман уку-укыту системасының барлыкка килү, үсеш үзенчәлекләрен һәм бүгенге торышын яктыртуга зур игътибар бирелде, мәктәп-мәдрәсәләрдә белем биргән педагогларның эш алымнары, тәҗрибәсе яктыртылды.

Татар педагогик фикере үсешендә педагогик матбугатның роле гаять зур. «Тәрҗеман» газетасы, XX гасыр башында дөнья күргән тәрбия-тәгълим журналлары («Мәктәп», «Укытучы», «Мөгаллим», «Тәрбия», «Мәгариф» һ.б.) укытучыларны һәм педагогика белән кызыксынучыларны татар мәгарифе, мәктәп-мәдрәсәләр тормышы, укыту методикасы, төрле предметларны укыту үзенчәлекләре, тәрбия һ.б. юнәлешләргә караган мәгълүматлар белән таныштырып барганнар. Революциягә кадәр махсус педагогик җәмгыятьләр, рәсми оешмалар булмау сәбәпле, алар үтәргә тиешле күп гамәлләр татар матбугаты тарафыннан башкарылган. Тәрбия-тәгълим журналлары битләрендә яңа дәреслекләр, укыту ысуллары һәм алымнары, педагогика фәне яңалыклары, башка халыкларның укыту һәм белем бирүдәге тәҗрибәләре турында мәгълүмат басылган. Бу басмалар бер үк вакытта педагогларның фикер алышу мәйданы ролен дә үтәгәннәр: аерым мәсьәләләр буенча бәхәсләр, дәреслекләрне апробацияләү, укытуда яңа юллар эзләү кебек чаралар кулланылган, дискуссияләрнең нәтиҗәләре тәкъдим ителгән. Соңгылары практик укытучыларның эшчәнлегендә тормышка ашырылган. XX гасыр башы татар матбугаты Антология төзүдә гаять кыйммәтле чыганак буларак файдаланылды. Әмма бүгенге көнгәчә барлык тәрбия-тәгълим басмаларының да библиографик күрсәткечләре булмау XX гасыр башы педагогик фикерен өйрәнүне беркадәр кыенлаштыра.

Татар педагогик фикере үсешендәге алда санап үтелгән чорларны, үсеш юнәлешләрен, аерым фикерләрне билгеләү шул фикерләр чагылыш тапкан текстларны һәм аларның авторларын – шәхесләрне барлауга юл ача. Антологиянең дә төп фәнни принцибы –

текстларны дөрес сайлап алу. Татар педагогик фикерен өйрәнүгә багышланган башка басмалардан аермалы буларак, Антологиядә текстларга яисә авторларның киңкырлы эшчәнлегенә анализ, характеристика бирелми. Ләкин шул ук вакытта авторның төп педагогик фикерләрен ачарлык, аның татар педагогик фикере үсешенә керткән өлешен күзалларга мөмкинлек бирерлек текстларны сайлап алу мөһим [30: 11]. Танылган галимнәрне, әйтик, тарихчы, дин әһеле, педагог буларак билгеле Ш.Мәрҗанине Антологиягә кертелгән шәхес буларак тәкъдим иткәндә, аның педагоглык эшчәнлегенә басым ясалды, төп педагогик фикерләрен чагылдырган хезмәтләре сайлап алынды.

Татар педагогик фикерен өйрәнүдә иң төп принципларның берсе – аз өйрәнелгән, педагогика белеме киңлегеннән төшеп калган, яңа исемнәрне фәнни әйләнешкә кертүдән гыйбарәт. Моңарчы аз билгеле булган, төрле сәбәпләр (нигездә сәяси) аркасында күләгәдә кала килгән, онытылуга дучар ителгән татар педагоглары шактый. Тикшеренүчеләр алдында торган төп бурычларның берсе – XIX-XX гасыр башында яшәгән һәм татар милләтенә хезмәт иткән, китаплары һәм мәкаләләре фәнни әйләнешкә кермәгән, репрессияләр чорында хезмәтләре юк ителгән педагог-галимнәрнең, укытучыларның педагогик мирасын бүгенге заман укучысына җиткерү. Шулай ук гарәп һәм латин графикаларында язылып, рус шрифтына күчерелмәгән күп санлы китап, дәреслек һәм методик әсбапларны өйрәнү, хәзерге графикага күчерү мәсьәләләре актуаль. Беренчедән, бу әлеге шәхесләребезнең исемнәрен кайтару, аларны киң җәмәгатьчелеккә таныту юлында башкарылган зур адым булса, икенчедән, татар педагогик фикере киңлеген, аның күпкырлылыгын һәм көчен күз алдына китерергә ярдәм итә. Бу үзенчәлекләр Антологиядә дә чагылыш тапты. Нәтиҗәдә, «Татар педагогик фикере антологиясе», үзенең эчтәлегенең байлыгы һәм күпкырлылыгы белән СССР халыкларының педагогик фикере антологияләреннән (алар нигездә бер кисәктән гыйбарәт һәм иң билгеле 10-15 шәхесне генә үз эченә алган) нигездә аерылып тора.

Татар педагогик фикере үсешен өйрәнүнең үзенчәлекле бер ысулы булган Антологиянең практик әһәмияте, иң беренче чиратта, аның татар педагогик фикерен өйрәнүчеләр өчен юнәлеш бирүендә. Мәгълүмати яктан бай булуы (аерым текстлардан тыш, аның авторы турында кыскача мәгълүмат (биографиясе), төп хезмәтләре исемлеге, автор турында басылып чыккан материаллар яисә архив чыганаклары бирелү) тикшеренүчеләргә уңайлыклар, киң катлам укучыларда татар педагогик фикере үсеше сәхифәләре белән кызыксыну тудыра. Махсус кушымталар – «Татар мәгарифе үсешенә өлеш керткән күренекле шәхесләр», «Татар телендә дөнья күргән тәрбия-тәгълим журналлары (XX гасырның беренче чиреге)», «Татарлар белем алган атаклы мәктәп-мәдрәсәләр», «Татар мәгарифе җитәкчеләре (халык мәгарифе комиссарлары һәм мәгариф министрлары) исемлеге» бирелү дә басманың практик әһәмиятен арттыра. Бу мәгълүматларның күбесе, әйтик, әлегәчә басылган хезмәтләре табылмау сәбәпле, Антологиягә кертелмәгән педагогларның исемлеге киләчәктә татар педагогик фикерен өйрәнүнең перспективалы юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек бирә. Җирле мәдрәсәләр тарихы (исемлеккә бары тик атаклы мәдрәсәләр генә кертелде), төбәкләрдә белем һәм тәрбия биргән мөгаллимнәр эшчәнлеге әлегәчә өйрәнелмәгән; татар мәгарифе үсешендә җирле үзенчәлекләрнең урыны; кулъязма дәреслекләр; дини тәрбиядә өлкәсендәге тупланган тәҗрибә; дини мәгариф системасының тарихы, эчтәлеге; традицион ислам; татар мәгърифәтчеләренең мирасы һ.б. мәсьәләләр – киләчәктә татар халкының педагогик фикере тарихын өйрәнүдә нәкъ менә шушы юнәлешләр нигез итеп алынырга тиеш.

Педагогик фикерне өйрәнүнең бер ысулы булган антологияләр төзү проекты, СССР таркалу белән тукталып калса да, беркадәр вакыттан соң концептуаль нигезләрен һәм юнәлешен үзгәрткән хәлдә торгызылды. 1995, 2012 елларда Казахстан педагогик фикере антологияләре дөнья күрде [31; 32]. 1994 елда заманча демократик җәмгыять идеалларына һәм кыйммәтләренә юнәлеш тоткан яңа дәреслек һәм уку-укыту әсбаплары төзүне максат иткән «Россиядә гуманитар белем бирүне яңарту» программасы нигезендә христиан педагогик фикере антологиясе басылып чыкты [33]. Юнәлешнең дәвамы буларак бүгенге көндә Россиядәге башка төп диннәрдәге педагогик фикерне барлау күзаллана. Татарларда педагогик фикер үсешенең аерылгысыз һәм иң мөһим өлеше булган ислам кыйммәтләре, мөселман диненең тәрбияви потенциалы, ислам дине белгечләренең тәрбия һәм белем турындагы

фикерләре галимнәр тарафыннан өйрәнүне көтә. Ислам диненең тәрбияви ролен ачыклау буенча беркадәр материал «Татар педагогик фикере антологиясе»ндә туплап бирелде. Киләчәктә аны тагын да киңәйтеп, Россия күләмендә өйрәнү һәм барлау, «Ислам педагогик фикере антологиясе»н («Мөселман педагогик фикере антологиясе»н) төзү юнәлешендә дәвам итәргә мөмкин. Татар педагогик фикерен өйрәнүнең тагын бер юлы – татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләрен педагогик күзлектән чыгып анализ ясау. Эшнең нәтиҗәсе фәнни-теоретик хезмәтләр, «Татар язучыларының педагогик фикере антологиясе»н төзү рәвешендә күздә тотыла.

**Әдәбият**


1. *Горохов В.М.* Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. Казань: Татгосиздат, 1941. 170 с.
2. *Горохов В.М.* Школьное образование среди татар Поволжья в XIX и в начале XX века. Казань, 1947. 50 с.
3. *Горохов В.М.* Педагогика тарихыннан очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1956. 124 б.
4. *Ханбиков Я.И.* Из истории педагогической мысли татарского народа. Казань, 1967. 232 с.
5. *Ханбиков Я.И.* История педагогики татарского народа. Казань, 1975. 162 с.
6. *Ханбиков Я.И.* Педагогика джадидизма // Педагогическая мысль в Казанском крае в конце XIX – начале XX вв. Казань: КГПИ, 1979. С. 52-71.
7. *Ханбиков Я.И.* Основные направления в развитии педагогической мысли татарского народа в XI-XX вв. Автореф. дис. … д.п.н. М., 1968. 27 с.
8. *Шарафутдинов З.Т.* Педагогическое пространство татарского народа. Казань, 2000. 180 с.
9. *Маликов Р.Ш.* Тюрко-татарская гуманистическая педагогическая мысль средневековья. Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. 304 с.
10. *Маликов Р.Ш.* Педагогическая мысль Ю.Баласагуни. Казань: КГПУ, 1999. 80 с.
11. *Маликов Р.Ш.* Педагогические идеи булгарского поэта Кул Гали. Казань: КГПУ, 1999. 112 с.
12. *Мухаметшин А.Г.* Становление и развитие педагогической мысли татарского народа в Казанском крае в VIII – нач. XX в. Автореф. дис. … д.п.н. Н.Новгород, 2009. 29 б.
13. Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. Казан: ТЭИ, 2008. 720 б.
14. Антология педагогической мысли Древней Руси и Русского государства XIV–XVII вв. / Сост. С.Д.Бабишин, Б.Н.Митюров. М.: Педагогика, 1985. 363 с.
15. Антология педагогической мысли Белорусской ССР /Сост. Э.К.Дорошевич, М.С.Мятельский, П.С.Солнцев. М.: Педагогика, 1986. 468 с.
16. Антология педагогической мысли Узбекской ССР /Сост. С.Р.Раджабов, К.Х.Хашимов, К.М.Муминходжаков. М.: Педагогика, 1986. 620 с.
17. Антология педагогической мысли Грузинской ССР / Сост. Д.Л.Гургенидзе, Н.В.Корзахия, Е.Г.Медзмариашвили. М.: Педагогика, 1987. 496 с.
18. Антология педагогической мысли Украинской ССР / Сост. Н.П.Калениченко. М.: Педагогика. 1988. 640 с.
19. Антология педагогической мысли Киргизской ССР / Сост. А.И. Акулова. М.: Педагогика, 1988. 368 с.
20. Антология педагогической мысли Азербайджанской ССР / Сост. А.А.Агаев, А.Ш.Гашимов. М.: Педагогика, 1989. 592 с.
21. Антология педагогической мысли России первой половины XIX в. / Сост. П.А.Лебедев. М.: Педагогика, 1987. 480 с.
22. Татар педагогик фикер антологиясен төзүнең методологик нигезләре / Төз. һәм җав. ред. Ф.М.Солтанов, Л.Р.Мортазина. Казан, 2006. 27 б.
23. Антология педагогической мысли России в XVIII в. / Сост. И.А.Соловков. М.: Педагогика, 1985. 480 с.
24. Антология по истории педагогики в России (первая половина XX века). М.: Academia, 2000. 384 с.
25. *Җәләлиев. Ш.Ш.* Милли тәрбия нигезләре. Казан: Мәгариф, 2003. 150 б.
26. *Давлетшин Г.* Культура Древних тюрков. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 63 с.
27. *Гыйбатдинов М., Мортазина Л.* Гасырлардан килгән хәзинә // Чын мирас. 2013. № 3. 57 б.
28. *Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш.* Булгарская цивилизация на Волге. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 111 с.
29. Татар педагогик фикере антологиясе. Т.1. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 407 б.
30. *Мортазина Л.* Татар педагогик фикер антологиясе // Мәгариф. 2006. №6. Б.11.
31. Антология педагогической мысли Казахстана / Сост. К.Жарыкбаев, С.Калиев. Алматы: Рауан, 1995. 512 с.
32. Антология педагогической мысли Казахстана / Сост. С.Калиев, К.Аюбай. Алматы, 2012. 464 с.
33. Антология педагогической мысли христианского Средневековья. В двух томах. Т.I. Путь христианского образования в трудах Отцов Церкви и мыслителей Раннего Средневековья / Сост. В.Г.Безрогов, О.И.Варьяш. М.: АО «Аспект Пресс», 1994. 400 с.

# ТЕОРЕТИЧЕСКИЕ И МЕТОДОЛОГИЧЕСКИЕ ОСНОВЫ ИЗУЧЕНИЯ ИСТОРИИ ТАТАРСКОЙ ПЕДАГОГИЧЕСКОЙ МЫСЛИ (НА ОПЫТЕ СОСТАВЛЕНИЯ «АНТОЛОГИИ ТАТАРСКОЙ ПЕДАГОГИЧЕСКОЙ МЫСЛИ»)

**Ляля Раисовна Муртазина,**
Институт истории Академии наук Татарстана,
Россия, 420014, г.Казань, Кремль, подъезд 5,
lyalyamur@mail.ru

В статье рассматривается проблема изучения татарской педагогической мысли как приоритетного направления в изучении истории татарской педагогики и просвещения. Определяются основные источники, теоретические и методологические основы, анализируется история и современное состояние изучения вопроса. Делается попытка определения роли межкультурных связей и ислама в развитии татарского просвещения. Одним из основных и значимых способов изучения педагогической мысли рассматривается составление «Антологии татарской педагогической мысли». Автор считает возможным отражение особенностей развития татарской педагогической мысли именно в рамках данного проекта. В статье также дается анализ антологий педагогической мысли разных народов СССР, вышедших в конце XX века, рассматриваются возможности применения опыта составления этих изданий в процессе работы над «Антологией татарской педагогической мысли». Автором определяются перспективные направления изучения татарской педагогической мысли.

**Ключевые слова:** татарская педагогическая мысль, антология, татарское просвещение, педагогическое наследие, народная педагогика, педагогическое пространство, межкультурные связи, новые имена.